МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 декабрь 2021 ел № М 512

Шәһәр Хакименең 2019 елның 10 гыйнварындагы М 07 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы карары, Шәһәр Советының «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазыйфаларында эшләүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/6 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2019 елның 10 гыйнварындагы М 07 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 пунктта:

- «айлык» сүзен төшереп калдырырга;

2) 27 пунктта:

- «айлык» сүзен төшереп калдырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктча өстәргә:

«13) тиешле җирле үзидарә органы хезмәтенә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә, 2018 елның 31 мартына билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары буенча еллык акчалата керем аермасын тигезләү өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү.»;

3) 28 пунктта:

- «муниципаль хезмәткәр белән ахыргы исәп-хисап ясалганда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев